**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Кариле авыл җирлеге Чаллы авылында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

28 нче декабрь 2019 ел № 8

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 нчы елның 26 нче ноябрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге территориясе, Чаллы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Чаллы авылы эчендәге һәм урамара юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- Чаллы авылы зираты коймасын ремонтлау;
- вакытлыча каты көнкүреш калдыклары полигоннарын карап тоту һәм чистарту;
- торак пункт эчендә (җәйге-көзге чорда) чүп үләннәрен чабу;
- Чаллы авылында су белән тәэмин итү системасын ремонтлау;».

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 119 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 61 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 61 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге составына керүче Чаллы авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге территориясе, Чаллы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм

алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Чаллы авылы эчендәге һәм урамара юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- Чаллы авылы зираты коймасын ремонтлау;

-вакытлыча каты көнкүреш калдыклары полигоннарын карап тоту һәм чистарту;

- торак пункт эчендә (җәйге-көзге чорда) чүп үләннәрен чабу*;*

- Чаллы авылында су белән тәэмин итү системасын ремонтлау;» соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга..

3. 2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге территориясе, Чаллы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:

-Чаллы авылы эчендәге һәм урамара юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- Чаллы авылы зираты коймасын ремонтлау;

- вакытлыча каты көнкүреш калдыклары полигоннарын карап тоту һәм чистарту;

- торак пункт эчендә (җәйге-көзге чорда) чүп үләннәрен чабу*;*

- Чаллы авылында су белән тәэмин итү системасын ремонтлау.

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы, Пионер урамы, 1;

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин урамы, 43;

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кече Кариле авылы, Вахитов урамы, 16, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Олы Кариле авыл җирлеге
башлыгы: Ф.Г. Гарифуллин